Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР**

№ 11 27.12.2018 ел

**2019 елга Аксубай муниципаль районының «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә коррупциягә каршы тору чаралары планын раслау турында»**

«Коррупциягә каршы тору турында» 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Президентының « Коррупциягә каршы торуның милли стратегиясе» 13.04.2010 № 460 Указына, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 04.05.2006 елгы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты коррупцион хокук бозуларны профилактикалау буенча карар чыгара::

1. Кушымтага ярашлы рәвештә «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә коррупциягә каршы тору чаралары планын расларга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, җәмәгать урыннарында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Ф.Х.Кәбиров

Кушымта
Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма
комитеты карарына
№ 11 , 27.12.2018 ел

**2019 елга Яңа Ибрай авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору буенча чаралар планы**

| Бүлекләр әм пунктлар | Чара | Башкару вакыты | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1. Коррупциягә каршы тору эшчәнлеген хокукый көйләүне камилләштерү һәм оештыру өлкәсендә чаралар** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.1. | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә туры китерү | ел дәвамында | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |
| 1.2. | Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү:<br>- муниципаль норматив хокукый актлар проектлары;<br>- муниципаль норматив хокукый актлар; | ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Аксубай МР башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы |
| 1.3. | Аксубай муниципаль районы башлыгы каршындагы Коррупциягә каршы тору комиссиясе белән хезмәттәшлекне тәэмин итү | ел дәвамында | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |
| 1.4. | Коррупциягә каршы тору өлкәсендә хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекне тәэмин итү | ел дәвамында | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |
| 1.5. | Расланган административ регламентларга ярашлы рәвештә муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты турында халык арасында мониторинг (сораштыру) үткәрү | даими | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |
| 1.6. | Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне оештыруны камилләштерү.<br>Гражданнарны кабул итү графигын раслау. | даими | АҖ башкарма комитет җитәкчесе АҖ башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 1.7. | Җирле үзидарә органында коррупция фактлары турында гражданнарның шикаятьләрен һәм мөрәҗәгатьләрен анализлау һәм күрсәтелгән фактларны тикшерүне оештыру(булган очракта) | Кварталга 1 тапкыр | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |
| **2. Кадрлар сәясәтен камилләштерү буенча чаралар** | | | |
| 2.1. | Коррупциягә каршы тору, муниципаль хезмәткәрләргә кагылышлы чикләүләрне бозу максатында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәмәүнең һәр очрагы буенча билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр үткәрү һәм тиешле юридик җаваплылык чараларын куллану.Эшне контрольдә тотуны көчәйтергә. | Үтәлмәү фактын билгеләгәндә | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.2. | Муниципаль хезмәткәрләр өчен хезмәт тәртибенә һәм хезмәт этикасына таләпләрне, коррупцион хокук бозулар һәм җинаятьләр өчен административ һәм җинаять җаваплылыгы мәсьәләләрен аңлату буенча киңәшмәләрдә катнашу | ел дәвамында | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |
| 2.3. | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупциягә каршы тору максатында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән бүләкләр алуга кагылышлы чикләүләр | ел дәвамында | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |
| 2.4 | Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре һәм чыгымнары турында мәгълүматны вакытында тутыру һәм тапшыру эшен оештыру | 2019 елның 30 апреленә кадәр | АҖ башкарма комитет җитәкчесе |
| **3. Муниципаль заказ урнаштыру өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү буенча чаралар** | | | |
| 3.1. | Сатуларны планлаштыру хисабына сатып алулар планын үтәүне тәэмин итү, еллык план-графикны раслау (мөмкин булган үзгәрешләрне исәпкә алып) һәм аны рәсми сайтта Интернет челтәрендә урнаштыру | ел дәвамында | АҖ хисапчысы |
| **4. Халыкка мәгълүмат бирү буенча чаралар** | | | |
| 4.1 | Авыл җирлеге территориясендәге учреждениеләрдә һәм оешмаларда коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аңлату эшләре алып бару | ел дәвамында | АҖ башлыгы, учреждение һәм оешма җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 4.2. | Аксубай муниципаль районы сайтында авыл җирлеге, мәгариф учреждениеләре һәм «Интернет " челтәрендәге мәгълүмат стендларында коррупциягә каршы тору буенча кабул ителә торган муниципаль хокукый актларны урнаштыру | ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 4.3. | Хуҗалык китапларыннан өзекләр бирүне контрольдә тоту. | ел дәвамында | АҖ башлыгы |
| 4.4. | Мәдәният һәм мәгариф бүлеге белән берлектә халык арасында коррупциягә каршы тору буенча аңлату эшләре үткәрү чаралары. Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган түгәрәк өстәлләр, әңгәмәләр үткәрү. Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре өчен учреждениеләрдә «ачыклык тартмалары» урнаштыру. | Квартал саен | АҖ башлыгы, учреждение һәм оешма җитәкчеләре (килешү буенча) |